ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре,
422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «20» февраля 2025 г.** **№ 24**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләү турында**

Татарстан Республикасы архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 19 апрелендәге “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү турында” 98/0 номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2023 елынң 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законы, 2024 елның 27 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы белән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 2025 елның “10” мартына билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар комиссиясе составын - коллегиаль киңәшмә органын расларга:

1) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - Р.М.Гатиятов;

2) Юридик мәсьәләләр буенча бүлек башлыгы — Л.Г.Сәгыйтова;

3) Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы — И.М.Хәсәнов;

4) Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге башлыгы — Р.Х. Батталова;

5) Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе — И.Г.Сиражиев.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны Урта Аты авыл мәдәният йорты бинасында 17:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә:

422016, Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк ур., 37 йорт.

4. Гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Арча муниципаль районы Советының 2022 елның 26 маендагы 145 номерлы карар белән расланган Нигезләмә нигезендә билгеләнгән тәртип буенча уздырырга.

5. Фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә, шулай ук чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00гә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү срогы - 09.03.2025 ел. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәргәндә язмача яисә телдән бирелергә мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетына:

- халыкка гавами тыңлаулар башлануы турында Арча муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырып хәбәр итәргә: https://arsk.tatarstan.ru, һәм авыл җирлегенең гавами тыңлауларда катнашучыларның күрсәтелгән мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итүче мәгълүмат стендларында:

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында һәм аңа мәгълүмати материаллар, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының яисә җыелышларының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүматлар;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүматлар һәм мондый проектка мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүматлар;

4) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенең яки экспозицияләренең урыны, ачылу датасы, мондый проектның экспозициясен яки экспозициясен үткәрү сроклары, күрсәтелгән экспозицияләрне һәм экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүматлар;

5) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар кертү тәртибе, срогы һәм рәвеше турында мәгълүматлар;

- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга https://arsk.tatarstan.ru;

- 26.02.2025 елдан 09.03.2025 елга кадәр авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча, халык тыңлауларында каралырга тиешле җирдән

файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының экспозицияләрен ачарга һәм үткәрергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк ур., 37 йорт. Экспозицияне эш көннәрендә 8:00 дән 16:00 гә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш;

- гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- гавами тыңлауларга әзерлекне, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән сроклар нигезендә уздыруны тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар йомгаклары буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://arsk.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе И. М. Хәсәновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль
районы башлыгы И.Г.Нуриев